КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 24 июнь г.Казань № 586

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 12 февраль, 38 нче; 2007 ел, 13 июль, 297 нче; 2009 ел, 23 март, 161 нче; 2009 ел, 15 июнь, 386 нчы; 2010 ел, 22 февраль, 92 нче; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2011 ел, 6 июнь, 452 нче; 2011 ел, 27 июнь, 515 нче; 2011 ел, 8 сентябрь, 750 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 29 март, 250 нче; 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 19 июнь, 524 нче; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2013 ел, 22 февраль, 128 нче; 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче; 2014 ел, 23 гыйнвар, 30 нчы; 2014 ел, 7 июнь, 388 нче; 2014 ел, 30 август, 630 нчы; 2014 ел, 12 сентябрь, 659 нчы; 2014 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 902 нче; 2014 ел, 3 декабрь, 940 нчы; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2016 ел, 15 апрель, 227 нче, 2016 ел, 20 август, 578 нче; 2017 ел, 3 февраль, 58 нче; 2017 ел, 16 март, 148 нче; 2017 ел, 19 июль, 508 нче; 2017 ел, 30 ноябрь, 930 нчы; 2017 ел, 15 декабрь, 999 нчы; 2017 ел, 29 декабрь, 1118 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

01.09.01.1 кодлы функция исемендә «каты көнкүреш алдыклары,» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

01.09.01.2 кодлы функция исемендә «каты көнкүреш алдыклары,» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 ел, 15 июнь, 468 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 20 декабрь, 1087 нче; 2011 ел, 29 июнь, 526 нчы; 2011 ел, 29 июль, 609 нчы; 2011 ел, 7 сентябрь, 747 нче; 2012 ел, 27 апрель, 330 нчы; 2012 ел, 30 июнь, 567 нче; 2012 ел, 30 июль, 645 нче; 2012 ел, 27 октябрь, 908 нче; 2013 ел, 19 март, 186 нчы; 2013 ел, 29 апрель, 296 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1111 нче; 2014 ел, 20 май, 332 нче;

2014 ел, 26 декабрь, 1039 нчы; 2015 ел, 10 март, 143 нче; 2016 ел, 26 февраль, 118 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 996 нчы; 2017 ел, 18 май, 291 нче; 2017 ел, 15 декабрь, 999 нчы; 2018 ел, 23 апрель, 278 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәдә:

3.1 нче пунктның дүртенче һәм бишенче абзацларында «каты көнкүреш калдыклары,» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

3.2 нче пунктның 3.2.4 нче пунктчасындагы дүртенче абзацта «каты көнкүреш калдыклары,» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

4 нче һәм 5 нче бүлекләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Дәүләт комитеты вәкаләтләре

Дәүләт комитеты үз компетенциясе чикләрендә түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

4.1. Электр энергетикасы өлкәсендә:

4.1.1. Электр энергиясен тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә тарифларның иң чик (минималь һәм (яки) максималь) дәрәҗәләрендәге тарифларны җайга салу өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән кысаларда милек хокукында яки башка законлы нигездә территориаль челтәр оешмаларына караган электр челтәрләре буенча электр энергиясен әлеге электр челтәрләре буенча тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә тарифлар билгели.

4.1.2. Электр энергиясен гарантияләүче кайтартучыларның сату өстәмә түләүләрен билгели.

4.1.3. Халыкка һәм аңа тиңләштерелгән кулланучылар категориясенә җибәрелә торган электр энергиясенә (куәтлегенә) бәяләрнең (тарифларның) иң чик (минималь һәм (яки) максималь) дәрәҗәләрендәге тарифларны җайга салу өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән кысаларда халыкка һәм аңа тиңләштерелгән кулланучылар категориясенә җибәрелә торган электр энергиясенә (куәтлегенә) бәяләр (тарифлар) билгели.

4.1.4. Электр энергиясенә (куәтлегенә) бәяләрнең (тарифларның) иң чик (минималь һәм (яки) максималь) дәрәҗәләрендәге тарифларны җайга салу өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән кысаларда халыкка һәм аңа тиңләштерелгән кулланучылар категориясенә җибәрелә торган күпләп сату базарының бәя зоналарына (электр энергиясеннән (куәтеннән) тыш) берләштерелмәгән территорияләрдә ваклап сату базарларында сатып алучыларга җибәрелә торган электр энергиясенә (куәтенә) бәяләр (тарифлар) билгели.

4.1.5. Энергиянең яңадан торгызыла торган чыганакларыннан файдалану нигезендә эшли торган квалификацияле генерацияләүче объектларда җитештерелгән һәм электр челтәрләрендәге югалтуларны компенсацияләү максатларында сатып алына торган электр энергиясенә бәяләр (тарифлар) яки аларның иң чик (минималь һәм (яки) максималь) дәрәҗәләрен билгели.

4.1.6. Законнар белән билгеләнгән очракларда, территориаль челтәр оешмалары өчен электр энергиясен тапшыру буенча хезмәт күрсәтүләр ышанычлылыгы һәм сыйфаты күрсәткечләренең план буенча һәм фактагы

мәгънәләрен билгели, шулай ук җылылык белән тәэмин итү объектлары ышанычлылыгы һәм сыйфаты күрсәткечләренең план буенча һәм факттагы мәгънәләрен билгели.

4.1.7. Электр энергетикасы өлкәсендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны гамәлгә ашыра.

4.1.8. Территориаль челтәр оешмаларының электр челтәрләренә технологик тоташу өчен түләү һәм (яки) бу түләүнең күләмен билгели торган стандартлаштырылган тариф ставкаларын билгели.

4.1.9. Территориаль челтәр оешмалары тарафыннан территориаль челтәр оешмаларының электр челтәрләренә технологик тоташу өчен түләүне һәм (яки) бу түләүнең күләмен билгели торган махсуслаштырылган тариф ставкаларын Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә куллану өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны гамәлгә ашыра.

4.1.10. Территориаль челтәр оешмалары тарафыннан электр челтәрләренә технологик тоташу өчен түләүне һәм (яки) бу түләүнең күләмен билгели торган стандартлаштырылган тариф ставкаларын куллануга бәйле булган бәхәсләрне җайга салуны гамәлгә ашыра.

4.1.11. Россия Федерациясе субъектлары буенча Россиянең бердәм энергетика системасы кысаларында электр энергиясен (куәтен) җитештерүнең һәм җибәрүләрнең җыелма фараз балансын формалаштыруда катнаша.

4.1.12. Электр энергетикасы субъектларының Дәүләт комитеты тарафыннан җайга салына торган бәяләргә (тарифларга) инвестиция программасын тормышка ашыру өчен кирәкле инвестиция ресурсларын кертү турындагы тәкъдимнәрен бәяләү һәм челтәрле оешмаларның (бердәм милли (гомумроссия) электр челтәре белән идарә итү оешмасыннан тыш) инвестиция программалары проектларының Дәүләт комитеты тарафыннан мондый челтәрле оешмаларның инвестиция программаларын формалаштыру максатыннан чыгып билгеләнгән хезмәт күрсәтүләр ышанычлылыгы һәм сыйфаты күрсәткечләренең максатчан мәгънәләренә туры килүен бәяләү өлешендә инвестиция программалары Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан раслана һәм тикшерүдә тотыла торган субъектларга кертелгән электр энергетикасы субъектларының инвестиция программаларын карап тикшерә.

4.1.13. Электр энергетикасы субъектларының Дәүләт комитеты тарафыннан җайга салына торган бәяләргә (тарифларга) инвестиция программасын тормышка ашыру өчен кирәкле инвестиция ресурсларын кертү турындагы тәкъдимнәрен бәяләү һәм челтәрле оешмаларның (бердәм милли (гомумроссия) электр челтәре белән идарә итү оешмасыннан тыш) инвестиция программалары проектларының Дәүләт комитеты тарафыннан мондый челтәрле оешмаларның инвестиция программаларын формалаштыру максатыннан чыгып билгеләнгән хезмәт күрсәтүләр ышанычлылыгы һәм сыйфаты күрсәткечләренең максатчан мәгънәләренә туры килүен бәяләү өлешендә инвестиция программалары Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан раслана һәм тикшерүдә тотыла торган субъектларга кертелгән территориаль челтәрле оешмаларның инвестиция программаларын килештерү процедурасында катнаша.

4.1.14. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гарантияләүче кайтартучылар тарафыннан электр энергиясенә (куәтенә) җайга салынмый торган бәяләр билгеләү һәм куллану турында» 2011 ел, 29 декабрь, 1179 нчы карары белән расланган Гарантияләүче кайтартучылар тарафыннан электр энергиясенә (куәтенә) җайга салынмый торган бәяләр билгеләү һәм куллану кагыйдәләренең гарантияләүче кайтартучылар тарафыннан үтәлешен тикшерүдә тотуны Россия Федерациясе Хөкүмәте белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

4.1.15. Ваклап сату базарлары эшчәнлегенең төп нигезләмәләрендә билгеләнгән тәртиптә гарантияләүче кайтартучыларны билгеләүдә яки алыштыруда һәм аларның эшчәнлекләре зоналары чикләрен билгеләүдә яки үзгәртүдә катнаша.

4.1.16. Россия Федерациясенең электр энергетикасы турындагы законнары нигезендә җайга салына торган бәяләр (тарифлар) дәрәҗәсенә һәм аларның үзгәрүенә йогынты ясаучы факторларга, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә электр энергиясенә (куәтенә) җайга салынмый торган бәяләр дәрәҗәсенә мониторинг гамәлгә ашыра.

4.1.17. Халыкка һәм аңа тиңләштерелгән кулланучылар категориясенә җибәрелә торган электр энергиясеннән (куәтеннән) файдалануның социаль нормасын билгели.

4.1.18. Россия Федерациясенең электр энергетикасы турындагы законнары нигезендә билгеләнгән һәм җайга салына торган бәяләр (тарифлар) турында, электр энергиясенә (куәтенә) җайга салынмый торган бәяләр һәм аларны куллану турында мәгълүмат җыюны гамәлгә ашыра.

4.1.19. Шәһәр торак пунктларында азык-төлек әзерләү өчен стационар электр плиталары һәм (яки) электр белән җылыту җайланмалары белән билгеләнгән тәртиптә җиһазландырылган йортларда яшәүче халык өчен электр энергиясенә бәяләргә (тарифларга) карата, шулай ук авыл торак пунктларында яшәүче халык өчен электр энергиясенә бәяләргә (тарифларга) карата төшерү коэффициентларын куллану турындагы карарны законнар нигезендә кабул итә.

4.1.20. Законнар белән билгеләнгән исемлек буенча халыкка тиңләштерелгән һәр категория өчен (законнарда күрсәтелгән аерым кулланучылардан тыш) җайга салуның тиешле чорына электр энергиясенә (куәтенә) бәяләрне (тарифларны) раслаганда аларга карата төшерү коэффициентларын куллану турындагы карарны законнар нигезендә кабул итә.

4.1.21. Тарифларны җайга салу өлкәсендә федераль башкарма хакимият органына электр энергиясенә (куәтенә) җайга салынмый торган бәяләрне билгеләү һәм куллану мәсьәләләре буенча мәгълүматны һәм кирәкле материалларны тарифларны җайга салу өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән мондый мәгълүматны бирү шартлары һәм исемлеге нигезендә кертә.

4.1.22. Тарифларны җайга салу өлкәсендә федераль башкарма хакимият органына «Электр энергетикасы турында» 2003 елында, 26 март, ФЗ-35 нче Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе субъектында төрле яклап субсидияләү күләме һәм аны этаплап кыскарту турында мәгълүмат кертә.

4.2. Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә:

4.2.1. Җылылык энергиясенә (куәтенә) тарифларның иң чик (минималь һәм (яки) максималь) дәрәҗәләрендәге тарифларны җайга салу өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән кысаларда электр һәм

җылылык энергиясен катнаш эшләү режимында 25 мегаватт һәм аннан да күбрәк тәшкил иткән электр энергиясе (куәте) җитештерүнең билгеләнгән генерацияләү куәте белән җылылык энергиясе чыганаклары белән җитештерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) тарифлар билгели.

4.2.2. Җылылык энергиясенә (куәтенә) тарифларның иң чик (минималь һәм (яки) максималь) дәрәҗәләрендәге тарифларны җайга салу өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән кысаларда җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан кулланучыларга җибәрелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) тарифлар, шулай ук җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җибәрелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) тарифлар билгели.

4.2.3. Җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан җылылык энергиясен (куәтен) кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җибәрелә торган җылылык чыганагына тарифлар билгели.

4.2.4. Җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җылылык белән тәэмин итүнең ачык системаларыннан (кайнар су белән тәэмин итүдән) файдаланып җибәрелә торган кайнар суга тарифлар билгели.

4.2.5. Җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә, җылылык чыганагына тарифлар билгели.

4.2.6. Җылылык энергиясеннән файдаланылмаганда резерв җылылык куәтен тәэмин итү хезмәтләре өчен түләү билгели.

4.2.7. Җылылык белән тәэмин итү системасына тоташу (технологик тоташу) өчен түләү билгели.

4.2.8. Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә тарифларга арттыру коэффициентларын билгели.

4.2.9. Россия Федерациясенең җылылык белән тәэмин итү турындагы законнары нигезендә җылылык энергиясенә (куәтенә) тарифларны җайга салуны өлешчә яки тулысынча гамәлдән чыгару турында, аны гамәлдән чыгарганнан соң җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә тарифларны җайга салуны гамәлгә кертү турында карар кабул итә.

4.2.10. Татарстан Республикасы законнары нигезендә җирле үзидарә органнарына тапшырылган вәкаләтләрне Россия Федерациясенең җылылык белән тәэмин итү законнары нигезендә үтәү йөзеннән кабул ителгән, әмма Россия Федерациясенең электр энергетикасы турындагы законнарына каршы килә торган яки аңа бирелгән компетенцияне арттырып кабул ителгән карарларны Россия Федерациясе Хөкүмәте белән билгеләнгән тәртиптә гамәлдән чыгара.

4.2.11. Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салына торган эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы оешмаларны инвестиция программаларын җирле үзидарә органнары белән килештереп раслый.

4.2.12. Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны гамәлгә ашыра.

4.2.13. «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-190 нчы Федераль закон белән күздә тотылган очракта, конкурс документларына кертелә торган җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) дәүләт

тарафыннане җайга салуның озак вакытка исәпләнгән параметрлары мәгънәләрен килештерүне гамәлгә ашыра.

4.2.14. Россия Федерациясенең концессия килешүләре турындагы законнары белән күздә тотылган очракларда, җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуның озак вакытка исәпләнгән параметрлары мәгънәләрен килештерүне, шулай ук аларга кертелә торган үзгәрешләрне алдан килештерүне гамәлгә ашыра.

4.2.15. Россия Федерациясенең концессия килешүләре турындагы законнары һәм «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-190 нчы Федераль закон нигезендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә тарифларны җайга салу ысулын сайлау турында концедентның яки конкурс оештыручының карарын килештерүне Россия Федерациясе Хөкүмәте белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

4.2.16. Конкурс оештыручы яки концедент соравы буенча конкурс документларына кертелә торган бәяләр, күләмнәр, мәгънәләр һәм параметрлар турындагы мәгълүматны җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә Россия Федерациясенең норматив хокук актлары белән билгеләнгән тәртиптә тапшыра.

4.2.17. «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-190 нчы Федераль закон белән билгеләнгән очракларда, бәяләр (тарифлар) билгеләү, аларны үзгәртү һәм төзәтү вакытында гамәлдә булган һәм федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокук актлары, Татарстан Республикасы законнары, шулай ук Татарстан Республикасының башка норматив хокук актлары белән күздә тотылган кагыйдәләр буенча аренда шартнамәсе гамәлдә булу вакыты чыкканга кадәр арендага алучы тарафыннан җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җитештерелә һәм реализацияләнә торган товарларга һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә җайга салына торган бәяләр (тарифлар) билгеләүне, аларны үзгәртүне һәм төзәтүне килештерә.

4.2.18. Россия Федерациясенең концессия килешүләре турындагы законнары белән билгеләнгән очракларда, бәяләр (тарифлар) билгеләү, аларны үзгәртү һәм төзәтү вакытында гамәлдә булган һәм федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокук актлары, Татарстан Республикасы законнары, шулай ук Татарстан Республикасының башка норматив хокук актлары белән күздә тотылган кагыйдәләр буенча концессия килешүе гамәлдә булу вакыты чыкканга кадәр җитештерелә һәм реализацияләнә торган концессия товарларына һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә җайга салына торган бәяләр (тарифлар) билгеләүне, аларны үзгәртүне һәм төзәтүне килештерә.

4.2.19. Җылылык энергиясенә (куәтенә) бәяләрнең иң чик дәрәҗәсен раслый.

4.2.20. Җылылык белән тәэмин итүнең бәя зоналарына кертелгән җирлекләрдә, шәһәр округларында, җылылык белән тәэмин итү оешмаларына, җылылык челтәре оешмаларына һәм кулланучыларга мәгълүмат бирү максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәте белән расланган җылылык белән тәэмин итүнең бәя зоналарында җылылык энергиясенә (куәтенә) бәяләрнең иң чик дәрәҗәсен билгеләү кагыйдәләре (җылылык энергиясенә (куәтенә) бәяләрнең иң чик дәрәҗәсен индексацияләү кагыйдәләрен кертеп), җылылык энергиясенә (куәтенә) бәяләрнең иң чик дәрәҗәсен исәпләп чыгару өчен кулланыла торган су кайнату казаннары һәм җылылык челтәрләре эшләвенең техник-икътисадый параметрлары

нигезендә билгеләнгән җылылык энергиясенә (куәтенә) бәяләр дәрәҗәсен исәпләп чыгаруны һәм аларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтта урнаштыруны тәэмин итә.

4.3. Газ белән тәэмин итү өлкәсендә:

4.3.1. Халыкка, шулай ук торак-эксплуатация оешмаларына, күпфатирлы йортлар белән идарә итүче оешмаларга, торак-төзелеш кооперативларына һәм торак милекчеләре ширкәтләренә халыкның көнкүреш ихтыяҗлары өчен реализацияләнә торган газга (торак йортларда торак булмаган бүлмәләрне арендага алучылар өчен, шулай ук автотранспорт чараларын тәэмин итү өчен газдан тыш) ваклап сату бәяләрен билгели.

4.3.2. Газ белән эшли торган җайланманы газ бүлү челтәрләренә технологик тоташтыру өчен түләү һәм (яки) аның күләмен билгели торган стандартлаштырылган тариф ставкаларын билгели.

4.3.3. Татарстан Республикасы территориясендә газ бүлү челтәрләре буенча газны транспортлауга тарифларны җайга салуда катнаша.

4.3.4. Газ бүлү оешмалары тарафыннан газ транспортлауга тарифларга махсус өстәмә түләү исәбеннән формалаштырыла торган газлаштыру программасын эшләүдә катнаша, әлеге махсус өстәмә түләү күләмен законнар нигезендә билгели, шулай ук аны кулланышка кертү нәтиҗәсендә алынган акчадан файдалану турындагы газ бүлү оешмалары хисапларына тикшерүләр үткәрә.

4.4. Су белән тәэмин итү һәм су чыгару өлкәсендә:

4.4.1. Салкын су белән тәэмин итү өлкәсендә тарифларның түбәндәге төрләрен билгели:

эчәргә яраклы суга (эчәргә яраклы су белән тәэмин итүгә);

техник суга;

суны транспортлауга;

су китерүгә (мондый тарифны билгеләү кирәклеге турында карар кабул иткән җирле үзидарә органнары мөрәҗәгать иткән очракта);

салкын су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасына тоташтыруга (технологик тоташтыруга).

4.4.2. Кайнар су белән тәэмин итү өлкәсендә тарифларның түбәндәге төрләрен билгели:

кайнар суга (кайнар су белән тәэмин итүгә);

кайнар суны транспортлауга;

кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасына тоташтыруга (технологик тоташтыруга).

4.4.3. Су чыгару өлкәсендә тарифларның түбәндәге төрләрен билгели:

су чыгаруга;

агызыла торган суларны транспортлауга;

су чыгаруның үзәкләштерелгән системасына тоташтыру (технологик тоташтыру) тарифына.

4.4.4. Капиталь төзелеш объектларын салкын, кайнар су белән тәэмин итүнең һәм су чыгаруның үзәкләштерелгән системаларына индивидуаль тәртиптә, законнар белән күздә тотылган очракларда һәм тәртиптә тоташтыру (технологик тоташтыру) өчен түләү билгели.

4.4.5. Су белән тәэмин итү һәм су чыгару өлкәсендә җитештерү программаларын раслый.

4.4.6. Кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су чыгаруны гамәлгә ашыручы оешма тарифларын җайга салу методларын сайлап ала.

4.4.7. Су белән тәэмин итү һәм су чыгару өлкәсендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны гамәлгә ашыра.

4.4.8. Җирле үзидарә органнарының аларга Россия Федерациясенең су белән тәэмин итү һәм су чыгару турындагы законнары нигезендә тапшырылган вәкаләтләр нигезендә кабул ителгән карарларын гамәлдән чыгара (әгәр дә мондый карарлар Россия Федерациясе законнарына каршы килсә).

4.4.9. «Су белән тәэмин итү һәм су чыгару турында» 2011 ел, 7 декабрь, ФЗ-416 нчы Федераль закон һәм Россия Федерациясенең концессия килешүләре турындагы законнары белән күздә тотылган очракларда, конкурс документларына кертелә торган тарифларны җайга салуның озак вакытка исәпләнгән параметрларын, ышанычлылык күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләрен, сыйфатны, энергетика нәтиҗәлелеген, тарифларны җайга салу ысулын килештерә.

4.4.10. Концессия килешүен төзү хокукына конкурс оештыручының соравы буенча «Су белән тәэмин итү һәм су чыгару турында» 2011 ел, 7 декабрь, ФЗ-416 нчы Федераль законның 41[1] статьясындагы 8 өлешнең 2 – 8 нче һәм 13 нче пунктларында күрсәтелгән бәяләрне, күләмнәрне, мәгънәләрне, параметрларны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су чыгару өлкәсендә тарифларны дәүләт җайга салуы турында» 2013 ел, 13 май, 406 нчы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм су чыгару өлкәсендә тарифларны җайга салу кагыйдәләре белән расланган тәртиптә бирә.

4.4.11. «Су белән тәэмин итү һәм су чыгару турында» 2011 ел, 7 декабрь, ФЗ-416 нчы Федераль закон белән билгеләнгән очракларда, тарифлар билгеләү, аларны үзгәртү һәм төзәтү вакытында гамәлдә булган һәм федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокук актлары, Татарстан Республикасы законнары, шулай ук Татарстан Республикасының башка норматив хокук актлары, җирле үзидарә органнарының хокук актлары белән күздә тотылган кагыйдәләр буенча аренда шартнамәсе гамәлдә булу вакыты чыкканга кадәр арендага алучы тарафыннан су белән тәэмин итү һәм су чыгару өлкәсендә җитештерелә һәм реализацияләнә торган товарларга, күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар билгеләүне, аларны үзгәртүне һәм төзәтүне килештерә.

4.4.12. Су белән тәэмин итү һәм су чыгару өлкәсендә җайга салына торган тарифларга кертелә торган инвестиция ресурслары күләмен килештерү өлешендә кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын раслау процедурасында, шулай ук әлеге инвестиция программаларын тормышка ашыруны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыруда катнаша.

4.4.13. Су белән тәэмин итү һәм су чыгару өлкәсендә җайга салына торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру шартлары турында килешүләр төзүдә катнаша.

4.4.14. Законнарда билгеләнгән очракларда, су белән тәэмин итү һәм су чыгару өлкәсендә билгеләнә торган тарифларга кагылышлы өлештә кайнар су белән тәэмин

итү, салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) су чыгарауның үзәкләштерелгән системалары объектларының ышанычлылыгы, сыйфаты, энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләрен раслау процедурасында катнаша.

4.4.15. Су белән тәэмин итү һәм су чыгару схемаларын эшләү һәм раслау мониторингын гамәлгә ашыруда катнаша.

4.4.16. Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларының техник-икътисадый торышы күрсәткечләре, шул исәптән кайнар су белән тәэмин итү, салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) су чыгару буенча үзәкләштерелгән системалар объектларының, салкын су белән тәэмин итү һәм кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелмәгән системалары объектларының энергетика нәтиҗәлелеге һәм физик тузу күрсәткечләре мониторингын гамәлгә ашыруда катнаша.

4.5. Калдыклар белән эш итү өлкәсендә:

4.5.1. Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә иң чик тарифларның түбәндәге төрләрен раслый:

каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторы хезмәтләренә бердәм тарифны;

каты коммуналь калдыкларны эшкәртүгә тарифны;

каты коммуналь калдыкларны йогышсызландыруга тарифны;

каты коммуналь калдыкларны күмүгә тарифны.

4.5.2. Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җитештерү программаларын раслый.

4.5.3. Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны гамәлгә ашыра.

4.5.4. Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен үткәрүдә катнаша.

4.6. Транспорт хезмәтләре өлкәсендә:

4.6.1. Шәһәр һәм шәһәр яны элемтәсендә җәмәгать транспортының (метрополитенны кертеп) барлык төрләре белән (тимер юл транспортыннан тыш) пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга тарифлар һәм (яки) иң чик (минималь һәм (яки) максималь) тарифлар билгели.

4.6.2. Шәһәр яны элемтәсендә огмуми кулланылыштагы тимер юл транспорты белән пассажирлар йөртү өлкәсендә табигый монополия субъектлары эшләренә (хезмәт күрсәтүләренә) икътисадый нигезләнгән дәрәҗәдә тарифларны, җыемнарны һәм түләүләрне, шулай ук әлеге йөртүләр өчен шәһәр яны элемтәсендә юл йөргәндә пассажирлар түли торган тарифларны, җыемнарны һәм түләүләрне һәм (яки) иң чик (минималь һәм (яки) максималь) тарифларны, җыемнарны һәм түләүләрне билгели.

4.6.3. Муниципальара һәм төбәкара маршрутлар буенча автомобиль транспортында (таксины кертеп) пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга тарифлар һәм (яки) иң чик (минималь һәм (яки) максималь) тарифлар билгели.

4.6.4. Җирле авиалинияләрдә, җирле элемтәдәге елга транспорты белән һәм кичүләрдә пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга тарифлар һәм (яки) иң чик (минималь һәм (яки) максималь) тарифлар билгели.

4.6.5. Теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешендәге сәнәгать тимер юл транспорты оешмалары һәм хуҗалык итүче башка субъектлар (федераль тимер юл транспорты оешмаларыннан тыш) тарафыннан поездлар керә торган тимер юлларда

күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә тарифлар һәм (яки) иң чик (минималь һәм (яки) максималь) тарифлар билгели.

4.6.6. Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлеген җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча гамәлгә ашыруга рөхсәтнамә һәм аның дубликатын бирү (яңадан рәсмиләштерү) өчен түләү билгели.

4.6.7. Татарстан Республикасында махсуслаштырылган куеп тору урыннарына тоткарланган транспорт чараларын күчерүгә, аларны саклауга тарифлар, шулай ук аларны түләү вакытларын билгели.

4.6.8. Тракторларның, үзйөрешле юл-төзелеш һәм башка машиналарның һәм аларның тагылмалары техник торышына, шулай ук агросәнәгать комплексында машиналарны һәм җиһазларны эксплуатацияләү кагыйдәләрен үтәүгә дәүләт күзәтчелеге үткәргәндә хезмәтләр күрсәтү өчен җыемнар күләмен билгели.

4.6.9. Татарстан Республикасы территориясендә транспорт чараларына техник тикшерү үткәрү өчен түләүнең иң чик күләмнәрен билгеләү (үзгәртү) турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертә.

4.6.10. Техник тикшерү үткәрү өчен түләүнең иң чик күләмнәрен һәм диагностика картасы дубликатын бирү өчен түләүнең билгеләнгән күләмнәрен үтәүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра.

4.6.11. Татарстан Республикасы һәм аның составына керә торган муниципаль берәмлекләр өчен халыкның техник тикшерү пунктлары белән минималь тәэмин ителеше нормативларын раслый.

4.6.12. Транспорт терминалларында, портларда һәм аэропортларда хезмәт күрсәтүләргә, шулай ук законнар белән күздә тотылган очракларда эчке су юлларыннан файдалану буенча хезмәт күрсәтүләргә тарифлар һәм (яки) иң чик (минималь һәм (яки) максималь) тарифлар билгели.

4.6.13. Татарстан Республикасы территориясендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы транспорт компанияләре турында мәгълүмат ачу стандартларының үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра.

4.7. Куллану базары өлкәсендә:

4.7.1. Яшәү өчен кирәкле һәм иң әһәмиятле дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларына дару препаратлары җитештерүчеләр билгеләгән факттагы җибәрү бәяләренә өстәмә күпләп сату бәяләренең иң чик күләмнәрен һәм өстәмә ваклап сату бәяләренең иң чик күләмнәрен билгели.

4.7.2. Социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан гражданнарга күрсәтелә торган социаль хезмәтләргә тарифлар һәм (яки) иң чик (минималь һәм (яки) максималь) тарифлар билгели.

4.7.3. Гомуми белем бирү оешмалары, һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары каршындагы җәмәгать туклануы предприятиеләрендә реализацияләнә торган продукциягә (товарларга) өстәмә арттырылган бәяләр һәм (яки) аларның иң чик (минималь һәм (яки) максималь) дәрәҗәләрен билгели.

4.7.4. Татарстан Республикасы территориясендә капиталь төзелеш объектларын техник инвентарьлаштыру һәм дәүләт техник исәбен алу өлкәсендә норматив хокук актлары белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган торак-фондка техник инвентарьлаштыру үткәрү ставкаларын билгели.

4.7.5. Законнар нигезендә орлыкчылык өлкәсендә түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бәяләр һәм тарифлар билгели.

4.7.6. Гражданнарга, идарә итүче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләренә, торак, торак-төзелеш яки Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның торакка булган ихтыяҗларын кәнәгатьләндерү максатларында төзелгән махсуслаштырылган башка кулланучылар кооперативларына реализацияләнә торган каты ягулыкка, көнкүреш мич ягулыгына бәяләр (тарифлар) һәм (яки) иң чик (минималь һәм (яки) максималь) тарифлар билгели.

4.7.7. Җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә торган кыйммәтен килештерә.

4.7.8. Татарстан Республикасы милкендә булган су объектларыннан файдалану өчен түләү ставкаларын, шулай ук исәп-хисап ясау һәм әлеге түләүне түләтү тәртибен билгели.

4.7.9. Татарстан Республикасы милкендә булган урман кишәрлеге мәйданының берәмлеге өчен һәм урман ресурслары күләме берәмлеге өчен, аны арендалау максатларында, түләү ставкаларын билгели.

4.7.10. Татарстан Республикасы милкендә булган җирләрдә әзерләнә торган агач күләме берәмлеге өчен түләү ставкаларын билгели.

4.7.11. Гражданнар өчен аларның үз ихтыяҗларына агач үсентеләрен сату-сатып алу шартнамәсе буенча түләү ставкаларын билгели.

4.7.12. Татарстан Республикасы территориясендә кадарстр эшләренең иң чик максималь бәяләрен раслый.

4.8. Башка өлкәләрдә:

4.8.1. Үз компетенциясе чикләрендә һәм законнар белән каралган очракларда, Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле башка товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) бәяләрне (тарифларны, өстәмә түләүләрне һәм өстәмәләрне һ.б.) җайга сала.

4.8.2. Эшчәнлекнең җайга салына торган төрләрен гамәлгә ашыручы оешмалар өчен, әгәр мондый оешмаларның товарларына һәм хезмәт күрсәтүләренә бәяләр (тарифлар) Дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнергә тиеш булган очракта, законнар нигезендә эшчәнлекнең җайга салына торган төрләренә карата энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү һәм энергия саклау өлкәсендәге программаларга таләпләр билгели.

4.8.3. Эшчәнлекнең җайга салына торган төрләрен гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан, әгәр мондый оешмаларның товарларына һәм хезмәтләренә бәяләр (тарифлар) Дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнергә тиеш булган очракта, энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү һәм энергия саклау өлкәсендә программалар кабул итү турындагы таләпләрнең һәм бу программаларга Дәүләт комитеты тарафыннан әлеге оешмалар эшчәнлегенең җайга салына торган төрләренә карата билгеләнә торган таләпләрнең үтәлешен тикшерүдә тотуны (аңа күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыра.

4.8.4. Тарифлар һәм бәяләр һәм (яки) аларның иң чик дәрәҗәләрен билгеләү турындагы тәкъдимнәргә экспертиза үткәрә, мондый экспертизаны чит оешмалар тарафыннан үткәрү турында карарлар кабул итә.

4.8.5. Эшчәнлекләрен җайга салына торган бәяләр билгеләү өлкәсендә гамәлгә ашыручы оешмаларның финанс-хуҗалык эшчәнлегенә анализ һәм оешмаларның финанс-икътисадый хәленә билгеләнгән бәяләрнең (тарифларның, өстәмә түләүләрнең, өстәмәләрнең һ.б.) тәэсиренә анализ ясый.

4.8.6. Татарстан Республикасында торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә түләгәндә гражданнарга субсидияләрне хисаплап чыгару өчен кулланыла торган гаиләнең җыелма керемендә торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә гражданнар чыгымнарының мөмкин булган иң күп өлешен һәм торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү кыйммәтен, субсидияләрне хисаплап чыгару өчен файдаланыла торган торак урынның норматив мәйданы төбәк стандартлары күләмнәрен билгели.

4.8.7. Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүнең төбәк стандартлары халыкның тормыш дәрәҗәсенең факттагы мәгънәләренә, торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү кыйммәтенә һәм халыкның торак мәйданы белән тәэмин ителешенә туры килү-килмәү турында хисап һәм төбәк стандартлары күрсәткечләрен вакытында алдан яңадан карау буенча тәкъдимнәр формалаштыру һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертү максатларыннан чыгып, индикаторларга квартал саен мониторинг (җыюны һәм анализлауны) үткәрүне гамәлгә ашыра.

4.8.8. Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре буенча коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең иң чик (максималь) индексларын раслау турында билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр формалаштыра һәм Татарстан Республикасы Президентының тиешле указ проектын Татарстан Республикасы Президенты Аппаратына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрә.

4.8.9. Татарстан Республикасы буенча уртача коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен һәм Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре буенча әлеге индекс күләменнән рөхсәт ителә торган иң тайпылу күләмен үзгәртү индексларын билгеләү турында билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр формалаштыра һәм алга таба тарифларны дәүләт җайга салуы өлкәсендә федераль башкарма хакимият органына кертү өчен тиешле исәп-хисапларны Татарстан Республикасы Президенты Аппаратына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрә.

4.8.10. Коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең иң чик (максималь) индексларын үтәүгә мониторинг үткәрүне гамәлгә ашыра.

4.8.11. Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле элемтә хезмәтләре тарифларына үзгәреш кертү турында тәкъдимнәр әзерли.

4.8.12. Эшчәнлеген җайга салына торган бәяләр билгеләү өлкәсендә гамәлгә ашыручы оешмалар исемлеген алып бара.

4.8.13. Үз компетенциясе нигезендә федераль башкарма хакимият органнары, аларның территориаль органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, Россиянең һәм чит илләрнең башка органнары һәм оешмалары белән төзелгән шартнамәләрнең, килешүләрнең һәм ачык-хокукый характердагы башка актларның реестрын алып бара.

4.8.14. Үз компетенциясе чикләрендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган Россия Федерациясендә хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыру методикасы нигезендә Татарстан Республикасында хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыра.

4.8.15. Үз компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү өчен Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә гражданнарга телдән һәм язмача хокукый консультация бирү рәвешендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтә.

Федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокук актлары белән билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә социаль ярдәмгә һәм социаль яклауга мохтаҗ гражданнарга гаризалар, шикаятьләр, үтенечнамәләр һәм хокукый характердагы башка документлар язу рәвешендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтә һәм судларда, дәүләт органнарында һәм муниципаль органнарда, оешмаларда граждан мәнфәгатьләрен яклый.

4.8.16. «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе турында» 2006 ел, 2 май, ФЗ-59 нчы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 ел, 12 май, ТРЗ-16 нчы Татарстан Республикасы Законы нигезендә билгеләнгән тәртиптә үзенең компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча гражданнарга телдән һәм язмача, шулай ук вәкаләтле зат тарафыннан шәхси кабул итү барышында ярдәм күрсәтә.

4.8.17. Дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) бәяләрне (тарифларны, өстәмә түләүләрне һәм өстәмәләрне һ.б.) куллану дөреслеге һәм аларның күләме нигезле булу өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны гамәлгә ашыра.

4.8.18. Россия Федерациясенең электр энергетикасы һәм җылылык белән тәэмин итү турындагы законнары нигезендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләргә (тарифларга) кертелә торган инвестиция ресурсларыннан файдалану өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны гамәлгә ашыра.

4.8.19. Газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлауны, эшчәнлеген тимер юл транспортында йөртүләр өлкәсендә, транспорт терминалларында, портларда һәм аэропортларда хезмәт күрсәтүләр һәм эчке су юллары инфраструктурасыннан файдалану буенча хезмәт күрсәтүләр өлкәләрендә гамәлгә ашыручы табигый монополияләр, электр энергиясенең күпләп һәм ваклап сату базарлары субъектларының, җылылык белән тәэмин итү оешмаларының, җылылык челтәре оешмаларының, каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторлары, каты коммуналь калдыклар белән эш итү операторлары, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмаларның мәгълүмат ачу стандартларын үтәве өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны гамәлгә ашыра.

4.8.20. Оешмалар, юридик зат белеме булмаган индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан бәяләр билгеләү буенча куелган тәртипнең үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра.

4.8.21. Дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны гамәлгә ашыручы орган функциясен Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турындагы кодекс нигезендә гамәлгә ашыра.

4.8.22. Үзгәрешләр кертү вәкаләтләре чикләрендә эшчәнлеген җайга салына торган бәяләр билгеләү өлкәсендә гамәлгә ашыручы оешмалар үтәү өчен мәҗбүри булган карарлар кабул итә һәм күрсәтмәләр бирә.

4.8.23. Табигый монополияләрне җайга салу буенча федераль башкарма хакимият органына табигый монополияне теге яки бу субъектка карата дәүләт җайга салуы кертү яки туктату өчен тәкъдимнәр кертә.

4.8.24. Җайга салу өлкәсендә федераль башкарма хакимият органына тарифларны Россия Федерациясе законнары нигезендә җайга салына торган бәяләрне (тарифларны, өстәмә түләүләрне, өстәмәләрне һ.б.) билгеләү, үзгәртү һәм куллану мәсьәләләре буенча мәгълүматны һәм кирәкле материалларны ул билгеләгән форматтагы сорау буенча кертә.

4.8.25. Торак-коммуналь хуҗалык буенча дәүләт мәгълүмат системасына «Торак-коммуналь хуҗалык буенча дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2014 ел, 21 июль, ФЗ-209 нчы Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат урнаштыра.

4.8.26. Мобилизация әзерлеген һәм Дәүләт комитетын, шулай ук эшчәнлекләре Дәүләт комитеты эшчәнлегенә бәйле яки аның карамагындагы өлкәдә булган оешмаларны мобилизацияләүне оештыра һәм тәэмин итә;

4.8.27. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән бәяләрне (тарифларны, өстәмә түләүләрне, өстәмәләрне һ.б.) дәүләт тарафыннан җайга салуга бәйле башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

## 5. Дәүләт комитетының хокуклары һәм бурычлары

5.1. Дәүләт комитеты үз вәкаләтләрен башкару өчен түбәндәге хокукларга ия:

5.1.1. Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, юридик һәм физик затлардан үзенә йөкләнгән бурычларны һәм функцияләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны, документларны һәм материалларны билгеләнгән тәртиптә сорарга һәм алырга;

5.1.2. Җирле үзидарә органнарыннан, эшчәнлекнең җайга салына торган төрләрен гамәлгә ашыручы оешмалардан электр һәм җылылык энергиясе өлкәсендә җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) билгеләү, үзгәртү һәм куллану мәсьәләләре буенча мәгълүматны һәм кирәкле материалларны Дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнгән формада һәм вакытларда сорарга һәм алырга;

5.1.3. Җирле үзидарә органнарыннан, эшчәнлекнең җайга салына торган төрләрен гамәлгә ашыручы оешмалардан электр энергиясенә (егәрлегенә) җайга салынмый торган бәяләрне билгеләү һәм куллану мәсьәләләре буенча мәгълүматны һәм кирәкле материалларны Дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнгән формада һәм вакытларда сорарга һәм алырга;

5.1.4. Җирле үзидарә органнарыннан һәм җайга салына торган оешмалардан муниципаль берәмлек территориясендә гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең иң чик (максималь)

индексларын билгеләү һәм куллану мәсьәләләре буенча мәгълүматны, шулай ук башка кирәкле белешмәләрне һәм материалларны Дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнгән формада һәм вакытларда сорарга һәм алырга;

5.1.5. Гражданнарның коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләменең тиешле муниципаль берәмлек өчен билгеләнгән иң чик индексларга туры килү-килмәве турында мәгълүмат җыюны гамәлгә ашырырга;

5.1.6. Кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) кулланылган суларны чыгаруны гамәлгә ашыруны оешмалардан, җирле үзидарә органнарыннан Россия Федерациясенең су белән тәэмин итү һәм су чыгару турындагы законнары, шулай ук башка федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокук актлары белән билгеләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле материалны сорарга;

5.1.7. Җылылык белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәре оешмалары, җайга салу органнары тарафыннан мәгълүматны ачу стандартлары нигезендә һәм әлеге оешмалар эшчәнлегенең тармак, технологик, структур, географик һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алып, җылылык белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәре оешмалары тарафыннан һәркемгә файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итә торган мәгълүматны кертү формасын һәм әлеге формаларны тутыру кагыйдәләрен расларга;

5.1.8. Законнар белән билгеләнгән үз вәкаләтләре чикләрендә җайга салына торган оешмалар тарафыннан үтәү өчен мәҗбүри булган карарлар кабул итәргә;

5.1.9. Законнар белән күздә тотылган очракларда бәяләрне (тарифларны, өстәмә түләүләрне, өстәмәләрне һ.б.) җайга салу (билгеләү) һәм бәяләр (тарифларны, өстәмә түләүләрне, өстәмәләрне һ.б.) билгеләүгә һәм куллануга бәйле мәсьәләләр буенча тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру өчен үз эшчәнлеге турында агымдагы хисапларны кертү тәртибен һәм вакытларны билгеләргә;

5.1.10. Җайга салына торган эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмаларның хуҗалык эшчәнлеген тикшерү нәтиҗәләре буенча, шулай ук җайга салына торган эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан тарифларны җайга салу өлкәсендә законнар белән күздә тотылган материаллар кертелмәгән очракта, күрсәтелгән оешмаларга карата җайга салынган алдагы чорлар өчен булган, шул исәптән гамәлдәге тарифларны билгеләү өчен файдаланылган мәгълүматлардан чыгып, бәяләрне (тарифларны) билгеләү турындагы мәсьәләне карап тикшерергә;

5.1.11. Тариф сәясәтен тормышка ашыру һәм тарифларны җайга салу өлкәсендә законнарны үтәү, җайга салына торган хезмәт күрсәтүләргә бәяләрне (тарифларны, өстәмә түләүләрне, өстәмәләрне һ.б.) раслау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма органнарының һәм җирле үзидарә органнарының хокук актларына анализ ясарга, бәяләр кую тәртибе һәм җайга салына торган бәяләрне (тарифларны, өстәмә түләүләрне, өстәмәләрне һ.б.) тикшерүдә тоту мәсьәләләре буенча аларга методик ярдәм күрсәтергә;

5.1.12. Бәяләрне (тарифларны, өстәмә түләүләрне, өстәмәләрне һ.б.) дәүләт тарафыннан җайга салуны хокукый һәм норматив-методик базасын камилләштерү турында тәкъдимнәр эшләргә;

5.1.13. Энергияне һәм ресурсларны саклау буенча дәүләт сәясәтен формалаштыруда һәм тормышка ашыруда, бу өлкәдәге эшчәнлекнең стратегик юнәлешләрен билгеләүдә катнашырга;

5.1.14. Энергияне һәм ресурсларны саклау белән дәүләт идарә итүе системасын һәм гамәлдәге норматив хокукый тәэмин итү системасын камилләштерүдә катнашырга;

5.1.15. Энергияне һәм ресурсларны саклау программаларын әзерләүдә катнашырга;

5.1.16. Дәүләт комитеты копметенциясе өлкәсендә эш итә торган ведомствоара, яраштыру, консультация органнары, иҗтимагый советлар һәм ассоциацияләр, экспертлар төркеме төзергә һәм аларның эшендә катнашырга;

5.1.17. Тарифларны җайга салу өлкәсендә федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасының махсуслаштырылган оешмалар белән килешүләр төзергә;

5.1.18. Законнар белән күздә тотылган очракларда җайга салына торган бәяләр (тарифларны, өстәмә түләүләрне, өстәмәләрне һ.б.) билгеләү өчен кирәкле документлар исемлеген, аларны кертү формасын һәм аларга карата таләпләрне расларга;

5.1.19. Үз компетенциясе мәсьәләләре буенча хокук актлары, шул исәптән Татарстан Республикасы территориясендә үтәү өчен мәҗбүри булган карарлар, нигезләмәләр, боерыклар, регламентлар, методик тәгълимнамәләр һәм күрсәтмәләр бастырып чыгарырга;

5.1.20. Судларга, шул исәптән арбитраж судларга, дәгъвалар һәм гаризалар белән мөрәҗәгать итәргә, шулай ук Дәүләт комитеты компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча законнарны бозуга бәйле эшләрне караганда катнашырга;

5.1.21. Физик һәм юридик затларга Дәүләт комитеты эшчәнлегенең билгеләнгән өлкәсендә закон бозуларны туктату һәм (яки) бетерү турында үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәләр җибәрергә;

5.1.22. Массакүләм мәгълүмат чараларында Дәүләт комитеты компетенциясе карамагындагы мәсьәләләрне яктыртырга;

5.1.23. Законнарда билгеләнгән тәртиптә экспертлар, эксперт оешмаларын җәлеп итәргә;

5.1.24. Дәүләт комитеты компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча семинарлар, киңәшмәләр үткәрергә;

5.1.25. Дәүләт комитеты эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләр буенча федераль башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмалар тарафыннан үткәрелә торган утырышларда, конференцияләрдә, утырышларда һәм башка чараларда катнашырга;

5.1.26. Законнар нигезендә башка хокукларны тормышка ашырырга.

5.2. Дәүләт комитеты түбәндәгеләргә бурычлы:

5.2.1. Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салганда законнарның үтәлешен тәэмин итәргә;

5.2.2. Җирле үзидарә органнарына һәм җайга салына торган оешмаларга бәяләр кую һәм тикшерүдә тоту мәсьәләләре буенча методик ярдәм күрсәтергә;

5.2.3. Гражданнарны кабул итүне оештырырга, гражданнарның һәм юридик затларның телдән әйтелгән һәм язма мөрәҗәгатьләрен үз вакытында һәм тулысынча карауны алар буенча карарлар кабул итүне һәм гариза бирүчеләргә билгеләнгән вакыт эчендә җаваплар җибәрүне тәэмин итәргә;

5.2.4. Үз эшчәнлеге турындагы хисапларны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга һәм тарифларны җайга салу өлкәсендә федераль башкарма хакимият органына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән вакытларда җибәрергә;

5.2.5. Татарстан Республикасы министрлыкларына, ведомстволарына идарә итүгә дәүләт заказы составында ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган Дәүләт комитеты эшчәнлеген бәяләү индикаторларына ирешүне тәэмин итәргә;

5.2.6. Дәүләт комитеты эшчәнлеге барышында барлыкка килгән архив документларын комплектлау, саклау, исәпкә алу һәм файдалану эшен гамәлгә ашыру;

5.2.7. Дәүләт комитеты хезмәткәрләрен һөнәри әзерләүне, аларны яңадан әзерләүне, аларның квалификациясен күтәрүне һәм стажировкасын оештырырга.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты структурасын бу карарга теркәлгән кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 ел, 5 август, 555 нче карары белән расланган Дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 нчы пунктта:

икенче абзацта «коммуналь комплекс оешмалары» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлауны, эшчәнлеген тимер юл транспортында йөртүләр өлкәсендә, транспорт терминалларында, портларда һәм аэропортларда хезмәт күрсәтүләр һәм эчке су юллары инфраструктурасыннан файдалану буенча хезмәт күрсәтүләр өлкәләрендә гамәлгә ашыручы табигый монополияләр, электр энергиясенең күпләп һәм ваклап сату базарлары субъектлары, җылылык белән тәэмин итү оешмалары, җылылык челтәре оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторлары, каты коммуналь калдыклар белән эш итү операторлары, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларын үтәү;».

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 26 сентябрь, 464 нче; 2005 ел, 1 ноябрь, 517 нче; 2005 ел, 29 декабрь, 661 нче; 2006 ел, 1 март, 87 нче; 2006 ел, 21 апрель, 198 нче; 2006 ел, 9 июнь, 293 нче; 2008 ел, 15 июль, 509 нчы, 2009 ел, 5 июнь, 360 нчы; 2009 ел, 17 август, 551 нче; 2010 ел, 8 июнь, 440 нчы;

2010 ел, 14 октябрь, 808 нче; 2010 ел, 2 декабрь, 976 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 7 октябрь, 838 нче; 2011 ел, 15 ноябрь, 935 нче; 2012 ел, 22 август, 726 нчы; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2013 ел, 18 февраль, 110 нчы; 2013 ел, 7 март, 152 нче; 2013 ел, 27 апрель, 286 нчы; 2013 ел, 10 август, 558 нче; 2014 ел, 21 апрель, 261 нче; 2015 ел, 1 июнь, 397 нче; 2016 ел, 13 декабрь, 925 нче; 2017 ел, 6 март, 127 нче; 2017 ел, 26 май, 309 нчы; 2017 ел, 14 ноябрь, 867 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.3 нче пунктның 3.3.4 нче пунктчасында ундүртенче абзацта «(газ белән тәэмин итү һәм электр белән тәэмин итү буенча ресурслардан һәм хезмәт күрсәтүләрдән тыш» дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2010 ел, 15 июнь, 468 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 24 июль, 586 нчы
карары редакциясендә)

## Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты структурасы

| Рәис | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Рәиснең беренче урынбасары | Рәис урынбасары | Рәис урынбасары | Эшләр идарәчесе | Ярдәмче |
| Җыелма бүлек | Коммуналь өлкә оешмаларын җайга салу идарәсе | Административ эшчәнлек бүлеге | Эш башкару бүлеге | Кадрлар бүлеге |
| Катнаш эшкәртүдәге җылылык энергиясенә тарифларны җайга салу бүлеге | Су белән тәэмин итү, су чыгару һәм каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә тарифларны җайга салу бүлеге | Транспорт хезмәтләре һәм элемтә хезмәтләре күрсәтүгә тарифларны җайга салу бүлеге | Тариф турында карарлар кабул итүне оештыру, тикшерүдә тоту һәм тәэмин итү бүлеге | Финанс-икътисад бүлеге |
| Электр энергиясенә тарифларны җайга салу бүлеге | Коммуналь өлкә оешмаларын мониторинглау һәм күзәтү бүлеге | Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге | Гомуми бүлек | Юридик бүлек |
| Технологик тоташтыру өчен түләүне җайга салу һәм тикшерүдә тоту бүлеге | Җылылык белән тәэмин итү оешмалары тарифларын җайга салу бүлеге | Куллану базары бәяләрен билгеләүне җайга салу һәм тикшерүдә тоту бүлеге | | Массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек итү мәсьәләләре буенча төп белгеч (пресс-секретарь) |
| Мәгълүматлаштыру бүлеге | Техник аудит һәм инвестиция программалары бүлеге | | | |

___________________________________________